ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 6 декабре** **Чистай шәһәре** **№ 735**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 февралендәге 93 номерлы карары белән расланган «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 17 ноябрендәге 2377-р номерлы, 2021 елның 20 гыйнварындагы 68-р номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2021 елга республика бюджеты акчаларыннан финанслау» 2 нче кушымтасына 7,8 пунктларын өстәргә.

1.2.«2021 елга җирле бюджет акчаларыннан финанслау» 3 нче кушымтасына 2 пунктны өстәргә..

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю. Задворновага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 6 декабрендәге
735 номерлы карарына
2 нче кушымта

2021 елга республика бюджеты акчаларыннан финанслау (мең сум)

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, инвентарь һәм экипировка сатып алу | ел дәвамында | 527,35 |
| 2 | Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә түләүләр | ел дәвамында | 27,30 |
| 3 | Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчыларга-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алган нәтиҗәләре өчен түләүләр | ел дәвамында | 2 100,00 |
| 4 | Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында, хоккей буенча Россия Федерациясе Чемпионатында спорт әзерлеге һәм катнашуы программаларын гамәлгә ашыру | ел дәвамында | 296,40 |
| 5 | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә физик культура, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыру, муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан спорт әзерлеге буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмәне финанс ягыннан тәэмин итү максатларында әлеге учреждениеләрдә шөгыльләнүче спортчыларны ташу буенча хезмәтләр аутсорсингка бәйле чыгымнар өлешендә. | ел дәвамында | 72,72 |
| 6 | Универсаль спорт мәйданчыклары һәм аз чыгымлы спорт корылмалары төзү | ел дәвамында | 54 131,35 |
| 7 | Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары һәм инвентарь сатып алу | ел дәвамында | 50,00 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләрнең муниципаль йөкләмәсен үтәү максатларында спорт объ-ектларының террорчылыкка каршы сакланышын тәэмин итү өчен җиһазлар сатып алуга бәйле рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыру | ел дәвамында | 162,50 |

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 6 декабрендәге
735 номерлы карарына
3 нче кушымта

2021 елга җирле бюджет акчаларыннан финанслау (мең сум)

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясендә физик культура, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыру, муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан спорт әзерлеге буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль йөкләмәне финанс ягыннан тәэмин итү максатларында әлеге учреждениеләрдә шөгыльләнүче спортчыларны ташу буенча хезмәтләр аутсорсингка бәйле чыгымнар өлешендә. | ел дәвамында | 0,72 |
| 2 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, физик культура һәм спорт өлкәсендә муниципаль учреждениеләрнең муниципаль йөкләмәсен үтәү максатларында спорт объектларының террорчылыкка каршы сакланышын тәэмин итү өчен җиһазлар сатып алуга бәйле рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыру | ел дәвамында | 1,62 |